КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 май г.Казань № 316

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче, 2023 ел, 05 август, 946 нчы, 2023 ел, 6 октябрь, 1252 нче, 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрү (01.06.15);»;

3.3 пунктта:

3.3.8 пунктчада:

бишенче абзацта «чара» сүзен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «чара» сүзен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

3.3.11 пунктчаның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрә;»;

3.3.12 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигын раслау хакында» 2022 ел, 5 февраль, 89 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 апрель, 394 нче, 2022 ел, 11 июль, 669 нчы, 2023 ел, 13 июль, 826 нчы, 2023 ел, 19 сентябрь, 1154 нче, 2023 ел, 20 декабрь, 1647 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигына, 13.4 пунктта «эчәргә яраклы су белән тәэмин итү һәм техник су белән тәэмин итү максатларында» сүзләрен «эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче, 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы, 2024 ел, 26 гыйнвар, 34 нче карарлары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре координаторына, «01.06.15» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрү».

4. Бу карар (бу карарның 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унынчы һәм унберенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин